# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасында җир өчен салымның вакытлы ставкаларын билгеләү турында**

Татарстан Республикасы Югары Советы КАРАР БИРӘ:

I. "Җир өчен түләүләр турында" Татарстан Республикасы Законын кабул иткәнчегә кадәр Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумына җир өчен салымның 1992 елга вакытлы ставкалары хакындагы, шулай ук Татарстан Республикасында җиргә хуҗа булу һәм аннан файдалану хокукына документлар рәвешләре турындагы мәсьәләне карарга һәм хәл итәргә.

2. Әлеге Законны аны кабул итү мизгеленнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты | М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1992 елның 10 июле
№ 1562-XII